КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь

г.Казань

№ 1334

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклап калуга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 28 сентябрь, 919 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклап калуга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 28 сентябрь, 919 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка «(Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклап калуга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәнең 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 нче кушымтасыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәненең 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1334 нче карары редакциясендә)

Мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төренең төп күрсәткечләре һәм максатчан зурлыклары, индикатив күрсәткечләре

Мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төренең төп күрсәткечләре

| Төп күрсәткеч | Төп күрсәткечне исәпләп чыгару формуласы | Төп күрсәткечнең максатчан зурлыклары |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Хисап чорында физик яктан тулысынча бетүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында карар кабул | $КП_1 = \frac{А_1}{Б_1} \times 100\%$,<br>монда:<br>$А_1$ – хисап чорында физик яктан тулысынча бетүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында карар кабул ителгән төбәк әһәмиятендәге, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары | иң күбе 15 процент |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| ителгән төбәк әһәмиятендәге, җирле (муниципаль) әһәмияттәге* мәдәни мирас объектлары өлеше** | саны;<br>$Б_1$ – төбәк әһәмиятендәге, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының гомуми саны | |
| Хисап чорында** зур күләмдә зыян күргән*** төбәк әһәмиятендәге, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары* өлеше | $$КП_2 = \frac{А_2}{Б_2} \times 100\%,$$<br>монда:<br>$А_2$ – хисап чорында зур күләмдә зыян күргән төбәк әһәмиятендәге, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары саны;<br>$Б_2$ – төбәк әһәмиятендәге, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының гомуми саны | иң күбе 15 процент |

Мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төренең индикатив күрсәткечләре

| Индикатив күрсәткеч | Индикатив күрсәткечне исәпләп чыгару формуласы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны; |
| Хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны | К,<br>монда К – хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында үткәрелгән инспекция визитлары саны | К,<br>монда К – хисап чорында үткәрелгән инспекция визитларының гомуми саны |
| Хисап чорында үткәрелгән рейдлар саны | К,<br>монда К – хисап чорында үткәрелгән рейдларның гомуми саны |
| Хисап чорында үткәрелгән документар тикшерүләр саны | К,<br>монда К – хисап чорында үткәрелгән документар тикшерүләрнең гомуми саны |
| Хисап чорында үткәрелгән күчмә тикшерүләр саны | К,<br>монда К – хисап чорында үткәрелгән күчмә тикшерүләрнең гомуми саны |
| Хисап чорында хезмәттәшлексез үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны | К,<br>монда К – хисап чорында үткәрелгән хезмәттәшлексез үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү чаралары (куркынычсызлык мониторингы) саны | К,<br>монда К – хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү чараларының (куркынычсызлык мониторингы) гомуми саны |
| Хисап чорында үткәрелгән күчмә тикшерүләр саны | К,<br>монда К – хисап чорында үткәрелгән күчмә тикшерүләрнең гомуми саны |
| Хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны | К,<br>монда К – хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның гомуми саны |
| Хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында белдерелгән кисәтүләр саны | К,<br>монда К – хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында белдерелгән кисәтүләрнең гомуми саны |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы | С<br>монда С – хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафларның гомуми суммасы |
| Хисап чорында йомгаклары буенча күрсәтмәләр бирелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – хисап чорында йомгаклары буенча күрсәтмәләр бирелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында йомгаклары буенча мәдәни мирас объектларын натурада саклап калу, аларны файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә йөкләмәләрне үтәүне мәҗбүр итү турында дәгъва гаризалары бирелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – Хисап чорында йомгаклары буенча мәдәни мирас объектларын натурада саклап калу, аларны файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә йөкләмәләрне үтәүне мәҗбүр итү турында дәгъва гаризалары бирелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында йомгаклары буенча мәдәни мирас объектын яисә чикләрендә археология мирасы урнашкан җир кишәрлеген милектән алу турында дәгъва гаризалары бирелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – хисап чорында йомгаклары буенча мәдәни мирас объектын яисә чикләрендә археология мирасы урнашкан җир кишәрлеген милектән алу турында дәгъва гаризалары бирелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында мәдәни мирас объектының аерылгысыз бер өлеше булган мәдәни мирас | К,<br>монда К – хисап чорында мәдәни мирас объектының |

| 1 | 2 |
|---|---|
| объекты территориясе чикләрендәге җир кишәрлеген яисә чикләрендә археология мирасы объекты урнашкан җир кишәрлеге түләүсез алу турында дәгъва гаризалары бирелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны | аерылгысыз бер өлеше булган мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендәге җир кишәрлеген яисә чикләрендә археология мирасы объекты урнашкан җир кишәрлеге түләүсез алу турында дәгъва гаризалары бирелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында йомгаклары буенча җинаятьләр билгеләре буенча җинаять эшләре ачу турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен вәкаләтле органнарга мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материаллар җибәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – хисап чорында йомгаклары буенча җинаятьләр билгеләре буенча җинаять эшләре ачу турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен вәкаләтле органнарга мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материаллар җибәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |
| Хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны | К,<br>монда К – хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризаларның гомуми саны |
| Хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны | К,<br>монда К – хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны |
| Хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектлар саны | К,<br>монда К – хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны |
| Хисап чоры ахырына төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары саны | К,<br>монда К – хисап чоры ахырына төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының гомуми саны |
| Хисап чоры ахырына төбәк (муниципаль) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары саны | К,<br>монда К – хисап чоры ахырына төбәк (муниципаль) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының гомуми саны |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Хисап чоры ахырына ачыкланган мәдәни мирас объектлары саны | К,<br>монда К – хисап чоры ахырына ачыкланган мәдәни мирас объектларының гомуми саны |
| Хисап чоры ахырына мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектлар саны | К,<br>монда К – исап чоры ахырына мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларның гомуми саны |
| Хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны | К,<br>монда К – хисап чорында аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны |
| Хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләр саны | К,<br>монда К – хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны |
| Хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны | К,<br>монда К – хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләрнең гомуми саны |
| Хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны | К,<br>монда К – Хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләрнең гомуми саны |
| Хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затла- | К,<br>монда К – хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү ту- |

| 1 | 2 |
|---|---|
| рының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында суд тәртибендә җибәрелгән дәгъва гаризалары саны | рында суд тәртибендә җибәрелгән дәгъва гаризаларының гомуми саны |
| Хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында суд тәртибендә җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны | К,<br>монда К – хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында суд тәртибендә җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризаларының гомуми саны |
| Хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны | К,<br>монда К – хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны |

---

*Төбәк әһәмиятендәге, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының гомуми санында.

**Хисап чоры календарь ел дигәнне аңлата.

***Зур күләм дигәндә Россия Федерациясе Җинаять кодексының 243.1 статьясында билгеләнгән, әлеге маддә буенча закон көченә кергән судлар хөкемнәре нигезендә алынган мәгълүмат буенча билгеләнә торган күләм аңлашыла.